РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» ноябрь 2024 ел г. Альметьевск № 3706

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә сервитут (гавами сервитут) билгеләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 25 июнендәге 916 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы, 2024 елның 22 июлендәге «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 194-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә сервитут (гавами сервитут) билгеләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 25 июнендәге 916 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 22 июлендәге 1547 номерлы, 2023 елның 18 апрелендәге 1019 номерлы, 2023 елның 28 ноябрендәге 7026 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарга 1 нче кушымтада:

2.10 пунктының исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле экспертлар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге».

регламентка 4 нче кушымтада:

Сервитут билгеләү турында Килешүгә кушымтада «Россия Икътисади үсеш министрлыгының «Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын әзерләү таләпләрен раслау турында, территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын электрон документ рәвешендә

әзерләгәндә территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы, әзерләү кәгазь чыганакта документ рәвешендә башкарыла торган территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы рәвешләрен раслау турында» 2014 елның 27 ноябрендәге 762 номерлы боерыгы» сүзләрен «Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең «Территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын әзерләү таләпләрен раслау турында, территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасын электрон документ рәвешендә әзерләгәндә территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы, әзерләү кәгазь чыганакта документ рәвешендә башкарыла торган территориянең кадастр планында җир кишәрлеген яисә җир кишәрлекләрен урнаштыру схемасы рәвешләрен раслау турында»2022 елның 19 апрелендәге П/0148 номерлы боерыгы» сүзләренә алмаштырырга

Регламентка 7 нче кушымтада «электр челтәрләренә, җылылык челтәрләренә, суүткәргеч челтәрләргә, су белән тәэмин итү челтәрләренә һәм (яисә) су бүлеп бирү челтәрләренә, газ белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру (технологик тоташтыру) турында килешү турында белешмәләр» сүзләрен «электр челтәрләренә, җылылык челтәрләренә, суүткәргеч челтәрләргә, су белән тәэмин итү һәм (яисә) су бүлеп бирү челтәрләренә, газ белән тәэмин итү челтәрләренә, элемтә линияләренә һәм корылмаларына тоташтыру (технологик тоташтыру) турында килешү хакында белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга.

регламентка кушымтаны (белешмә) яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.А. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы — А. М. Каюмов

Муниципальное образование «Альметьевский муниципальный район» Республика Татарстан
Татарстан Республикасы «Әлмәт муниципаль районы» муниципаль берәмлеге
Р06-12061/12
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ
ИНН 1644035822
КПП 164401001
ОГРН 1051605067172

Муниципаль милектәге җир кишәрлегенә сервитут (гавами сервитут) билгеләү буенча кушымта (белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы һәм аның үтәлешен тикшереп торучы вазыйфаи затларның реквизитлары

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты

| Фамилия Исеме Атасының исеме | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| Каюмов Айдар Марат улы | Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе | 39-01-03 | priemnay2012@gmail.com |
| Ямалетдинов Аяз Әнис улы | Район башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары | 39-01-90 | Ayaz.Y@tatar.ru |

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы

| Фамилия Исеме Атасының исеме | Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|---|
| Кузьмина Татьяна Николаевна | Комитет рәисе урынбасары | 26-10-37 | T.Kuzmina@tatar.ru |
| Абдуллина Эльмира Рафыйк кызы | Җир мөнәсәбәтләре бүлеге башлыгы | 26-10-37 | pzio@mail.ru |